Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл җирлеге Советы Карары

28 май 2020 ел

№ 130

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Советының «Күңгәр авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 11 ноябрендәге 109 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләр белән) нигезендә, предприятиеләрнең, оешмаларның, учреждениеләрнең, вазыйфаи затларның һәм гражданнарның санитар һәм экологик торышлары өчен җаваплылыгын арттыруны һәм тикшереп торуны көчәйтү һәм авыл җирлеге территориясендә чисталык һәм тәртип саклау максатыннан Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Советының «Күңгәр авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 11 ноябрендәге 109 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**27 статьяның 16 пунктындагы 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.**

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы Г.Х.Гарипова